**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» апреля 2020 с. Тюлячи № 200

Эш көне булмаган көннәр чорында Теләче муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны карап торган өчен ата-аналар түләвен исәпләүне һәм алуны туктатып тору турында

МКУ «Теләче муниципаль районы башкарма комитеты» мәгариф бүлеге» начальнигының 2020 елның 9 апрелендәге 114 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Президентының «яңа коронавирус йогышы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында»2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указы белән билгеләнгән эш көне булмаган чорда Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны карап торган өчен ата-аналар түләвен исәпләүне һәм алуны туктатып торырга.
2. МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» (Карпова Н.В.), МКУ «Теләче муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» (Павлова Л.П.), Теләче муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д. С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов